Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советының унөченче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2018 елның 20 сентябре № 104

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы “Җирле референдум турында” законының 12, 17 статьялары, Питрәч авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы КАРАР чыгарды:

1. Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты белән берлектә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә: “2019 елда яшәү урыны Питрәч авыл җирлеге чикләрендә урнашкан, 18 яшькә җиткән һәр Россия Федерациясе гражданыннан 500 сум үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны киләсе эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме:

- Питрәч авылында тротуарлар төзү;
- Олан Иле авылында балалар мәйданчыгы төзү;
- Шихазда авыл эчендәге юлларны ремонтлау.

Аерым мәсьәләләр буенча акча экономияләнгән очракта, Питрәч авыл җирлеге башкарма комитетына референдум тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә,

ӘЙЕ ЮК”.

2. Әлеге карарны Питрәч авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында халыкка игълан итәргә һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә.

Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов